Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Иске Роман авыл җирлеге Советы

Карар

2025 елның 16 октябре №3/2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советының «Торглар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында, җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында, хосусый милектәге җир кишәрлекләренең мәйданын арттыру өчен аларның муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән яңадан бүлешүе нәтиҗәсендә түләү күләмен билгеләү тәртибе турында һәм җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибе хакында» 2025 елның 27 мартындагы 57/4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге Советының «Торглар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында, җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында, хосусый милектәге җир кишәрлекләренең мәйданын арттыру өчен аларның муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән яңадан бүлешүе нәтиҗәсендә түләү күләмен билгеләү тәртибе турында һәм җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибе хакында» 2025 елның 27 мартындагы 57/4 номерлы карарының 1 нче кушымтасы белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Иске Роман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында Нигезләмәгә, 1

нче кушымтаның 3 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
«2) бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтенә, мондый ширкәт әгъзасына бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән бакча җир кишәрлеге яисә яшелчә җир кишәрлеге;».
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтына www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Р.Г. Дәүләтшина